КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 декабрь г.Казань № 1108

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карарына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру чараларын тормышка ашыру буенча эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетының финанс чыгымнары нормативларын раслау турында» 2021 ел, 10 ноябрь, 1062 нче карары үз көчен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 660 нчы, 2006 ел, 19 июнь, 312 нче, 2010 ел, 31 май, 419 нчы, 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче, 2011 ел, 26 октябрь, 890 нчы, 2011 ел, 23 декабрь, 1060 нчы, 2012 ел, 2 июнь, 466 нчы, 2012 ел, 10 октябрь, 846 нчы, 2013 ел, 19 март, 185 нче, 2013 ел, 4 декабрь, 955 нче, 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче, 2014 ел, 4 июнь, 376 нчы, 2016 ел, 19 март, 150 нче, 2016 ел, 29 октябрь, 796 нчы, 2017 ел, 3 февраль, 58 нче, 2017 ел, 20 апрель, 232 нче, 2017 ел, 18 декабрь, 1008 нче, 2018 ел, 22 март, 161 нче, 2018 ел, 5 июнь, 430 нчы, 2018 ел, 17 декабрь, 1155 нче, 2019 ел, 16 март, 185 нче, 2019 ел, 22 июль, 613 нче, 2020 ел, 11 февраль, 99 нчы, 2020 ел, 11 июль, 575 нче, 2020 ел, 19 август, 710 нчы, 2021 ел, 21 гыйнвар, 19 нчы, 2021 ел, 18 июнь, 476 нчы, 2021 ел, 6 декабрь, 1168 нче, 2022 ел, 22 апрель, 389 нчы, 2022 ел, 1 июнь, 511 нче, 2022 ел, 18 август, 852 нче, 2022 ел, 2 сентябрь, 946 нчы, 2022 ел, 1 ноябрь,

1165 нче, 2022 ел, 5 декабрь, 1288 нче, 2022 ел, 30. декабрь, 1485 нче, 2023 ел, 12 апрель, 451 нче, 2023 ел, 09 июнь, 704 нче, 2023 ел, 2 август, 936 нчы, 2023 ел, 31 август, 1058 нче, 2024 ел, 20 май, 339 нчы, 2024 ел, 24 июнь, 453 нче, 2024 ел, 4 июль, 500 нче, 2024 ел, 30 октябрь, 942 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «2 484,729» саннарын «2 609,133» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәнең 3.3 пунктында:

йөз җиденче һәм йөз сигезенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру эшләрен уздыруны, шул исәптән юл хәрәкәте мониторингын тәэмин итә;

төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын урнаштыру, алмаштыру, сүтү һәм карап тоту эшләрен башкаруны тәэмин итә;»;

һөз унберенче абзацка «, юл хәрәкәтен оештыруның күрсәтелгән проектларына үзгәрешләр» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«җирле әһәмияттәге автомобиль юллары йә аларның участоклары өчен, бүтән автомобиль юллары йә аларның муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан участоклары өчен эшләнә торган юл хәрәкәтен оештыру проектларын, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары йә аларның участоклары, бүтән автомобиль юллары йә аларның муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан участоклары төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларына тоташкан очракта, юл хәрәкәтен оештыруның күрсәтелгән проектларына үзгәрешләрне килештерә;

хосусый автомобиль юллары яисә аларның участоклары өчен юл хәрәкәтен оештыру проектларын, хосусый автомобиль юллары йә аларның участоклары төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларына тоташкан яисә аларны кисеп чыккан очракта, юл хәрәкәтен оештыруның күрсәтелгән проектларына үзгәрешләрне килештерә;

муниципаль район, шәһәр округы яисә шәһәр җирлеге йә аларның өлешләре өчен, шулай ук уртак чиге булган берничә муниципаль район, шәһәр округлары яисә шәһәр җирлекләре территорияләре өчен эшләнә торган юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемаларын, юл хәрәкәтен оештыруның расланган мондый комплекслы схемаларына үзгәрешләрне килештерә.».

2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру чараларын тормышка ашыру буенча эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетының финанс чыгымнары норма-тивларын раслау турында» 2021 ел, 10 декабрь, 1062 нче карарының үз көчен югалтуын танырга.

2. Әлеге карар, бу карарның 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы икенче абзацыннан тыш, 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры А.В.Песошин